| ГЛАВА ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 нчы ноябрь 2021 ел Ябалак авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Ябалак авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставының 22маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.2021 елның 23 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Ябалак авылы, Якты урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Ябалак авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2.2021 елның 24 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Ябалак авылы, Латыйф Хәмиди урамы, 19А нчы йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Ябалак авылында **үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Ябалак авыл җирлеге Ябалак авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән

500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып күперне ремонтлау;

*б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, материаллар сатып алып контейнер мәйданчыкларын җиһазлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://ebalak-kaybici.tatarstan.ru

7. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Ябалак авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (GOVID-19) авыру очракларын кисәтү һәм таратуга каршы профилактик,санитар-эпедемик чараларының үтәлешен тәэмин итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.